***Халык бәйрәмнәр календаре:***

***Июнь***

Сабантуй - татарларның иң билгеле милли бәйрәме. Бу бәйрәмне язгы кыр эшләре беткәч, июнь айлаларының соңгы көннәре аралыгында үткәрәләр. Бәйрәмнең конкрет датасы юк, ул шул язгы кыр эшләренең кайчан бетүенә бәйле. Сабантуй - чынлап торып массакүләм күңел ачу һәм спорт чарасы, бу чарада профессионал спортчылар гына түгел, ә бәйрәмгә килгән һәр тамаша кылучы катнаша ала.

***Июль***

20. Мөселманнарның зур бәйрәмнәренең берсе - Корбан гаете. Ул Ураза бәйрәменнән соң 70 көн узгач, Зөлхиҗҗә аеның 1нчы көнендә билгеләп үтелә. Гарәп теленнән Корбан сүзе карубә ягъни якынаю дигән сүз. Шәригатьтәге мәгънәсе гамәл гыйбадәт белән Аллаһыга якынаю, димәк, без намаз укуыбыз, Корбан чалуыбыз белән Аллаһыга якынаябыз.

***Август***

30. Татарстан Республикасы көне Татарстанның тарихи, әһәмиятле көннәре арасында Республика көне аерым урын алып тора. Бу бәйрәм дәүләтчелегебез үсешендә яңа чорны гәүдәләндерә. Ул җәмгыять тормышының бөтен якларын демократияләштерүдә, республикабыз халкының рухи һәм интеллектуаль мөмкинлекләренә юл ачуда мөһим этап булды.

***Уен «Капчык киеп йөгерү»***



**Уен барышы: Балалар** ике колоннага тезеләләр. Сигнал буенча, капчыкларын ике яктан бил турысында тотып, билгеләнгән урынга кадәр йөгерәләр.Беремне беренче булып төгәлләгән команда җиңүче була.

*Кемнәр өлгер, кемнәр җитез,*
*Минем янга килегез.*
*Әйдә, карыйк ярышып,*
*Капчык киеп чабышып.*

***Уен «Йомырка салынган кашык белән йөгерү»***



**Уен барышы:** Уенчылар, сигналбулу белән, кашыкның сабыннан тоткан клеш, йомырканы төшермәскә тырышып, алдан билгеләнгән урынга кадәр йогерәләр. Кашыктан йомырканы төшермичә, старт сызыгына беренче булып килгән уенчы җиңүче була.

*Кашыкка салып күкәйне*
*Йөгерегез тизрәк.*
*Күрик әле, бу ярышта*
*Кайсыгыз җитезрәк?*

***Уен «Чиләк белән су ташу»***



**Уен барышы:** Катнашучылар бер рәткә тезелеп басалар. Яннарында сулы савыт.Уенчылар сигнал бенча су ташый башлыйлар. Кем тизрәк ташый һәм стаканын беренче булып тутыра, шул җиңүче була.

*Менә сиңа агач кашык,*
*Су салырсың эченә.*
*Йөгер тизрәк, иң алдан кил,*
*Егыла гына күрмә.*

**Җәй** - ел фасылының иң матур чагы. Кайсы ягын гына алсаң да, мактап бетереп булмас төсле. Табигать җәй аенда керфекләрен ача төсле.

**Җәй** – июнь чәчәкләр ае. Шушы айда болын-кырлар гына түгел, юкәләр дә чәчәккә күмелә. Бу айда бал кортлары армый-талмый эшлиләр, бал җыеп калырга тырышалар.



Җәй аеның көтеп алган, күркәм бәйрәмнәренең берсе булган Сабантуйлар. Тәрбия һәр халыкта аның теле белән бергә барлыкка килгән. Күп гасырлар буена ул, кшелекне дәвам иттерү чарасы буларак, табигый ихтиаҗ булып яшәп килгән. Яшь буын өлкәннәр белән аралашкан, тормышта кирәкле күнекмәләргә, кешеләр арасында үз-үзен тотарга, аралашырга өйрәнгән, халыкның гореф гадәтләрен, йолаларын өлкән буын ярдәме белән үзләштерелгән.

Сабантуй бәйрәмен яңа укыту методик комплекты программасы буенча без балалар белән әзерләнәбез һәм үткәрәбез. Бәйрәмгә җыйналган халык милли уеннар уйнаганнар: чүлмәк вату, капчык сугышы, аркан тартыш, капчык киеп йөгерү, таяк тартышы, кул көрәше.



**Җәйге болында**

Кызыл, сары, зәңгәр, күк…
Бик күп төрле чәчәкләр
Сабантуйга җыелган.
Яңгыр үтте, җил тынды,
Күр салават күперен –
Бар да шуннан коелган:
Кызыл, сары, зәңгәр, күк…

## Халык сынамышлары

- *Җәй көне гел томан булса, гөмбә күп булыр.*
- *Беренче күк күкрәү кыйбла ягыннан булса, иген уңар.*
- *Салават күпере элек күренгәндә кайсы яктан күренсә, шул яктагы ашлык уңар.*
- *Томан күп төшсә, җимеш уңар.*
- *Июнь өчесендә булса төшлектән җил - сабан ашлыгына килә ел.*
- *Тавыклар оя басарга соң утырып иртә торсалар, ачлык булыр.*
- *Кура җиләге дә, каен җиләге дә күп булса, киләсе елга арыш яхшы булыр.*
- *Чыпчыклар чыркылдашса, көн җылыта.*
- *Август аенда аяз булса, көз пычрак булыр.*

**Казан шәһәре Совет районының «Татар телендә тәрбия һәм белем бирүче 64 нче катнаш төрдәге балалар бакчасы» мәктәпкәчә белем муниипаль бюджет учреждениесе**

# Халык календаре

*җәйге халык уеннары*